Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай Выселкасы җирлеге Советы

КАРАРЫ

14.12.2023 ел № 39/4

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалаган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган күчемсез милекне читләштерү турындагы нигезләмәне раслау хакында»24.09.2019 ел, №77/2 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2019 елның 24 сентябрендәге 77/2 номерлы Выселкасы авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалана торган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне тартып алу турында нигезләмәгә, 5.2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4) әлеге Федераль закон нигезендә мондый шартнамәнең яклары тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган башка шартлар, шулай ук мондый шартнамәнең үзара килешү буенча яклар тарафыннан билгеләнгән башка шартлар.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай Выселкасы авыл җирлеге
башлыгы С.А. Ефимов